КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 11 декабрь г.Казань № 1077

Спортның олимпия төрләре буенча спорт әзерлеге буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында

Дәүләт оешмалары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатын яхшырту максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Спортның олимпия төрләре буенча спорт әзерлеге буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын расларга.
2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына муниципаль учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган тиешле муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын бәяләү өчен әлеге карар белән расланган Спортның олимпия төрләре буенча спорт әзерлеге буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын куллануны тәкъдим итәргә.
3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Спортның олимпия төрләре буенча спорт әзерлеге буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында» 2017 ел, 19 июль, 509 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спортның олимпия төрләре буенча спорт әзерлеге буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында» 2017 ел, 19 июль, 509 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 7 июнь, 479 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 ел, 3 сентябрь, 776 нчы.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин